| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ТУЕМБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТУЕМБАШ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

с.Туембаш

2022 елның 24 октябре № 12

Туембаш авыл җирлеге башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыяри (волонтер) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри (волонтер) оешмалар белән хезмәттәшлеге тәртибе турында» 2018 елның 18 декабрендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярилык (волонтерлык) турында «Федераль законның 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 июлендәге 340-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Туембаш авыл җирлеге башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыяри (волонтер) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри (волонтер) оешмалар белән хезмәттәшлеге тәртибе турында» 2018 елның 18 декабрендәге 3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтаның 3 пунктында:

1) дүртенче абзацта «күрсәтүнең» сүзен гадәттән тыш хәлләрне һәм аларның нәтиҗәләрен бетерүдә, янгыннарны кисәтүдә һәм сүндерүдә, һәлакәттән коткару эшләрендә катнашу, шулай ук күрсәтүнең» сүзләренә алмаштырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле абзацны өстәргә:

«гражданнарның хәбәрсез югалган затларны эзләүдә катнашуы.».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып, халыкка игълан итәргә; шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ф.Гарипов